Татарский язык (для татароязычных учащихся).
7 класс.

1. Русчага тәрҗемә итегез.

Әтием турында

Минем әтием – сезгә таныш (мин шулай дип уйлыйм) композитор Салих Сәйдәшев. Аның балачагы турында мин әбиемнән сөйләтә идем. Ул миңа әтиемнең бик тере, әмма тыңлаучан һәм мәктәптә теләп укый торган малай булуы турында сөйли иде. Әбием сөйләгәннәрдән мин тагын шуны белеп алдым: әтием бик кечкенәдән музыка тыңларга, җырларга яраткан, гармунда уйнарга бик иртә өйрәнгән. Көндәлек тормышта әтием йомшак, киң күңелле, һәркемнең күңелен күрә белүче кеше булды. Мин аның безгә, балаларга, кайчан да булса кычкырганын хәтерләмим.

2. Җавапларны языгыз. Саннарны сүзләр белән языгыз.

7 көн — ? 24 сәг — ? 30 (яки 31) көн — ? 100 ел — ? 10 мм — ? 100 см — ? 1000 м — ? 10 см — ? 1000 г — ? 100 кг — ? 10 ц — ? 10 көн — ?

3. Түбәндәге саннар кергән сүзләр языгыз.

6, 1, 2, 3, 10, 100

4. “Мода нәрсә ул?” дигән темага фикер йөртү тексты (инша) языгыз. (6 җөмлә).